ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында” Федераль законның $16^6$ һәм $16^{6-1}$ статьяларын гамәлгә ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

“Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында” Федераль законның $16^6$ һәм $16^{6-1}$ статьяларын гамәлгә ашыру чаралары хакында” 2012 елның 28 декабрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“**Татарстан Республикасында гражданнарның эконом класслы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында**”;

2) 1 статьяда “Федераль законның (алга таба – Федераль закон) $16^6$ статьясындагы 36 өлеше, $16^{6-1}$ статьясындагы 20 өлеше” сүзләрен “Федераль закон (алга таба – Федераль закон)” сүзләренә алмаштырырга, “, шулай ук “Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2014 елның 21 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарның эконом класслы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга сала”;

3) 2 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

“6) “Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2014 елның 21 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарның эконом класслы торак сатып алу хокукына ия категорияләре исемлеген раслый, җирле

үзидарә органнары тарафыннан мөрәҗәгать итүче гражданнарның эконом класслы торак сатып алу хокукына ия гражданнарның билгеләнгән категорияләренә туры килүен тикшерү тәртибен, җирле үзидарә органнары тарафыннан эконом класслы торак сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен төзү һәм раслау тәртибен, аларга үзгәрешләр кертү тәртибен, шулай ук мондый исемлеккә кертелгән гражданнарның Татарстан Республикасы буенча җыелма реестрын алып бару тәртибен һәм күрсәтелгән реестрда булган белешмәләрне Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә эконом класслы торак төзү максатларында территорияләрне үзләштерү турында шартнамәләр яисә эконом класслы торак төзү максатларында территорияләрне комплекслы үзләштерү турында шартнамәләр төзегән юридик затларга бирү тәртибен билгели.»;

б) 2 өлештә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2) Федераль законның 11 статьясындагы $6^8$ һәм $6^9$ өлешләре нигезендә, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тәкъдимнәренә таянып, эконом класслы торак төзелешенә ихтыяҗ булу турында үтенечнамә (алга таба – үтенечнамә) әзерли һәм Фонд тарафыннан алга таба Федераль законның $16^6$ – $16^{6-2}$ статьяларында каралган аукционнар үткәрү максатларында Фондка җибәрә;”;

3 пунктта “җир кишәрлекләре” сүзләреннән соң “, дәүләт милке итеп алынмаган җир кишәрлекләре” сүзләрен өстәргә;

5 пунктта “җир кишәрлекләрен” сүзләреннән соң “, дәүләт милке итеп алынмаган җир кишәрлекләрен” сүзләрен өстәргә, “$16^6$, $16^{6-1}$ статьялары” сүзләрен “$16^6$ – $16^{6-2}$ статьялары” сүзләренә алмаштырырга;

4) 3 статьяның 2 өлешендәге 3 пунктының “б” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“б) муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан, эконом класслы торак төзү өчен аукционнар үткәрелергә мөмкин федераль милектәге яисә дәүләт милке итеп алынмаган җир кишәрлекләре турында;”;

5) 6 статьяның 9 өлешендә “Федераль законның $16^{16-1}$ статьясындагы 30 өлешенең 2 пунктында” сүзләрен “Федераль законның $16^{16-1}$ статьясындагы 30 өлешенең 2 пунктында һәм $16^{16-2}$ статьясындагы 31 өлешенең 2 пунктында” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 16 марты
№ 16-ТРЗ